РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БИЕКТАУСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Х.Сафиуллина ул., дом 4,
с. Биектау, 422665

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИЕКТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Х. Сафиуллина урамы, 4 нче йорт,
Биектау, 422665

Тел.: (884361)32-5-26, факс: 32-5-26. E-mail:biek.rs@tatar.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның 15 ноябре Биектау авылы № 3

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Биектау, Околоток-Янгасала, Чаллыбаш, Яңавыл авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Биектау авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Биектау авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 25 ноябрендә 11 сәг. 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Биектау авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2021 елның 25 ноябрендә 14 сәг. 00 минутка билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Околоток-Янгасала авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 26 ноябрендә 11 сәг. 00 минутка билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Чаллыбаш авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 29 ноябрендә 11 сәг. 00 минутка билгеләргә.
5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Яңавыл авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 30 ноябрендә 11 сәг. 00 минутка билгеләргә
6. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү территориаль билге буенча гамәлгә ашырылуын расларга.
7. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Биектау, Околоток-Янгасала, Чаллы-Баш, Яңавыл авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Биектау, Околоток-Яңасала, Чаллы-Баш т.п. суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү (запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт күрсәтү);
- Биектау, Околоток-Яңасала, Чаллы-Баш т.п. су белән тәэмин итү системасын карап тоту (тирән насослар сатып алу);
- Биектау, Околоток-Яңасала, Чаллы-Баш, Яңавыл т.п. урамнарын яктыртуны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (килешү буенча);
- Биектау, Околоток-Яңасала, Яңавыл авыллары урамнарның юл өлешен (урамнарны чистарту) кышкы чорда кардан чистарту;
- җәйге чорда Биектау, Околоток-Яңасала, Чаллы-Баш, Янавыл (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)торак пунктларында территорияне чабу;
- Биектау т. п. балалар мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру;
- Биектау т. п. З. Шәймәрдәнов, К. Насыйри урамнары буенча урам юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алу;
- Яңавыл т. п. Киров урамы буенча урам юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алу;
- Биектау торак пунктында су белән тәэмин итү системасын рәсмиләштерү;
- Биектау авыл мәдәният йорты өчен теннис өстәле сатып алу

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

6. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Биектау авылы, Х. Сафиуллин урамы, 4 йорт;Околоток-Яңасала авылы, Калинин урамы, 102 йорт; Чаллыбаш авылы, М. Горький урамы, 69 һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

7. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы А.Р.Гилазиева